| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**24.09.2019** г.Кукмор **№ 526**

Опека һәм попечительлек органының
аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы
оешмалар эшчәнлегенә контрольлек итү
тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау
хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары белән расланган Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 5 пунктына, Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 10.01.2009 елгы 4 номерлы «Балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек башкаруның аерым мәсьәләләрен гамәлгә ашыру турында»гы боерыгына таянып, **карар бирәм:**

1. Балигъ булмаган гражданнарның опекуны яки попечительләре, йә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка төр формаларда тәрбиягә кабул итәргә теләк белдерүче гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлегенә контрольлек итү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга (Кушымта).

2. Әлеге карарны ТР Хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р.Х. Галиевага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Кушымта
Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең
24.09 2009 ел № 526 карарына

Балигъ булмаган гражданнарның опекуны яки попечительләре, йә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка төр формаларда тәрбиягә кабул итәргә теләк белдерүче гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешмалар эшчәнлегенә контрольлек итү тәртибе турында

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип «Опека һәм попечительлек турында» 24.04.2008 ел, № 48-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 18.05.2009 ел, №423 карары белән расланган мәгариф оешмалары, медицина оешмалары, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалар яки башка оешмалар, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмалар тарафыннан балигъ булмаган балаларга карата опека һәм попечительлек органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 5 пунктын һәм Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 13.03.2015 ел, № 235 "Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенең 24 пунктына үзгәрешләр кертү хакында" боерыгы белән расланган карарын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты белән балигъ булмаган гражданнарның опекуннары яки попечительләре булырга йә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка төр формаларда тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органы вәкаләтләрен тапшыру турында шартнамәләр төзелгән оешмаларның эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен билгели (алга таба – опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләт).

1.2. Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 10.01.2019 ел, №4 «Балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек башкаруның аерым мәсьәләләрен гамәлгә ашыру турында»гы Боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча оешма эшчәнлеген контрольдә тоту Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген контрольдә тоту мондый оешма эшчәнлегенә тикшерүләр үткәрү юлы белән башкарыла.

2. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерүне үткәрү регламенты

2.1. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерү балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек буенча вәкаләтле вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы «Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек башкаруның аерым мәсьәләләре турында» карары нигезендә гамәлгә ашырыла.
2.2. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеген тикшерүне Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының бер вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яки Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаручы кимендә ике муниципаль хезмәткәре составында комиссия үткәрә ала, шуларның берсе – комиссия рәисе.
2.3. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерү планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.
2.3.1. Планлы тикшерү булып Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган, тиешле календарь елга формалаштырыла торган һәм тикшерү планына кертелгән тикшерү тора.
2.3.2. Бер оешманы планлы тикшерү килешү нигезендә балигъ булмаган гражданнарның опекуннары һәм попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны әзерләү өчен юллама бирелгән очракта елга бер тапкырдан артык үткәрелми.
2.3.3. Планлы тикшерү оешманың урнашу һәм эшчәнлек алып бару урынында (урынга чыгып тикшерү) үткәрелә.
2.4. Тикшерү планына кертелмәгән тикшерү планнан тыш тикшерү була.
2.4.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, түбәндәге очракларда планнан тыш тикшерү үткәрә:

опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда оешма тарафыннан аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга карата гражданнарның шикаять белән мөрәҗәгате;

дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, башка оешмалардан һәм гражданнардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан оешма эшчәнлегендә опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча эшчәнлектә гамәлдәге закон нормаларын бозу турында мәгълүмат керү.

Планнан тыш тикшерү урынга чыгып яки урынга чыкмыйча, әлеге пунктта күрсәтелгән очраклар туганда, чикләнмәгән күләмдә үткәрелә.

2.5. Оешма эшчәнлеген опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда тикшергәндә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия әгъзалары хокуксыз:

- әлеге вәкаләтне гамәлгә ашыруга карамаган гамәлдәге законнар таләпләренең үтәлешен тикшерергә;

тикшерү предметына кагылмаган документларны, мәгълүматны тапшыруны таләп итәргә;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән тикшерү үткәрү срокларын арттырырга.

2.6. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерү максатында вазыйфаи зат (муниципаль хезмәткәр) оешмага тикшерүне үткәрү турында мәгълүмати хат җибәрүне тәэмин итә, анда түбәндәге мәгълүматлар урын ала:

тикшерү формасы турында (урынга чыгып, урынга чыкмыйча);

тикшерү төре турында (планлы, планнан тыш);

тикшерү үткәрү вакыты турында (башлану һәм тәмамлау датасы). Тикшерү үткәрү турында мәгълүмати хат оешмага тикшерү башланганчы 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.7. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) йә комиссия әгъзалары хокуклы:

тикшерү максатларына ирешүгә кирәкле тикшерелүче чор өчен барлык документларны (мәгълүматны) соратып алырга, шулай ук тикшерү барышында барлыкка килгән мәсьәләләр буенча язмача һәм телдән аңлатмалар таләп итәргә;

тикшерү материалларына катнаштыру өчен, тикшерү предметына кагылышлы документларның күчермәләрен ясарга.

2.8. Урынга чыгып тикшерү үткәрүнең гомуми срогы (урынга чыгып тикшерү) 2 (ике) эш көненнән артмаска тиеш.

2.9. Күчмә тикшерү тәмамланганнан соң, 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, оешманың вазифаи затларының материалларын, документларын һәм аңлатмаларын өйрәнү нәтиҗәләреннән чыгып, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия тарафыннан тикшерү акты төзелә.

2.9.1. Тикшерү акты кәгазьдә ике нөсхәдә рәсмиләштерелә.

2.9.2. Тикшерү акты үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

- тикшерү актын төзү датасы, тикшерү үткәрү урыны һәм, көннәр санын күрсәтеп, тикшерү үткәрү срогы турында;

- тикшерү рәвеше һәм формасы турында;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты карарының тикшерү үткәрелгән датасы һәм номеры турында,

- тикшерү үткәрелгән оешманың исеме турында;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма

комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) йә тикшерү уздыра торган комиссия әгъзалары турында (комиссия рәисен дә күрсәтеп);

- тикшерү үткәрү өчен оешма тарафыннан тапшырылган (тапшырылмаган) документлар (мәгълүмат) турында;

- опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен тормышка ашырганда оешма эшчәнлегендә ачыкланган хокук бозу фактлары, аларның характеры һәм эчтәлеге турында;

- оешма тарафыннан опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлегендәге ачыкланган хокук бозу һәм җитешсезлекләрне тикшерү тәмамланган датага бетерү турында;

- тикшерү нәтиҗәләре турында гомумиләштерелгән мәгълүмат һәм нәтиҗәләр;

- оешма җитәкчесененең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы яки танышудан баш тартуы турында белешмәләр.

2.9.3. Тикшерү акты Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) йә комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана. Тикшерү актына кул кую мөмкинлеге булмаган очракта, комиссиянең аерым әгъзалары тарафыннан тикшерү актында тиешле имза булмауның сәбәбе турында тамга куела.

2.9.4. Тикшерү актына тикшерүгә кагылышлы документлар яки аларның күчермәләре, шул исәптән ачыкланган бозулар өчен җавап бирүче оешманың вазыйфаи затларының аңлатмалары теркәлә.

2.9.5. Тикшерү актының бер нөсхәсе оешма җитәкчесенә, Башкарма комитет җитәкчесе раслаганнан соң, 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.10. Урынга чыкмыйча тикшерү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия тарафыннан булган документларны, шулай ук оешмадан соратыла һәм алына торган документларны, оешманың вазыйфаи затларының аңлатмаларын карау юлы белән үткәрелә.

2.10.1. Оешма җитәкчесе тикшерү үткәрү турында мәгълүмат хатында күрсәтелгән срокта опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлегенә кагылышлы соратып алына торган барлык документларны тапшырырга тиеш

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет тарафыннан урынга чыкмыйча тикшерү нәтиҗәләре турында белешмә әзерләнә.

Белешмә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан килештерелә. Белешмә оешмага заказлы хат белән, аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе килештергәннән соң, 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә

Балигъ булмаган гражданнарның опекуны яки попечительләре, йә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка төр формаларда тәрбиягә кабул итәргә теләк белдерүче гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оештыру эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмәгә
Кушымта

Балигъ булмаган гражданнарның опекуны яки попечительләре, йә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка төр формаларда тәрбиягә кабул итәргә теләк белдерүче гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оештыру эшчәнлеген
ТИКШЕРҮ ПЛАНЫ

| Тикшерү ешлыгы | Тикшерү үткәрү ае | Тикшерү үткәрү вакыты |
|---|---|---|
| елга 1 тапкыр | ноябрь | 2 көн |